# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

25.03.2024 ел № 6

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 мартындагы «2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 1 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Иске Урыссу торак пунктының Инеш, 1 Май урамнары буенча юлларын норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Хәтер скверы территориясен хезмәтләндерү (килешү буенча эш өчен түләү);

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (торак пункт юллары эчендә тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

4) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, ремонт, койма тоту, (зиратта хуҗалык инвентаре өчен бина төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

5) торак пункт территориясен төзекләндерү (милли Сабантуй бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)?».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова